**“Яттан сөйлим Тукай шигырьләрен”**



24 нче апрель көнне гимназиядә “Яттан сөйлим Тукай шигырьләрен” дип исемләнгән нәфис сүз остасы бәйгесе булып узды. Бәйгедә катнашучы 1-10 сыйныф укучылары Габдулла Тукай иҗатыннан 1 әсәр әзерләп , уңышлы гына чыгыш ясадылар. Бәйге укучыларның татар әдәбияты белән кызыксынуын арттыру, татар телен тирәнтен үзләштерү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен булдыру, сәләтле балаларны барлау максатыннан эшләнде.